Россия Эчке эшлэр министр-лыгынын Саранск шэhэре буенча идарэсе Ленин районы терри-ториясендэ жинаятьлэрне тикшерv бvлеге тарафыннан 30 яшьлек жирле хатын-кызга карата кылынган мошенниклык факты буенча жинаять эше кузгатылган. Зыян кvрvче сvзлэренчэ, январь ахырында ук ана vзен иминият (страховая) компаниясе хезмэткэре дип таныштырган билгесез кыз кэгазь медицина полисын электрон полис ка алыштыру кирэклеге турында хэбэр иткэн. Чит кеше анлатканча, мошенниклар анын шэхси кабинетына керv момкинлеге алган, шуна бэйле счетларда саклана торган акчаларны ашыгыч рэвештэ куркынычсызландырырга, шулай ук анын исеменнэн санкциялэнмэгэн кредит рэсмилэштерvгэ комачаулый торган процедуралар vткэрергэ кирэк, дигэн. Аннары сойлэшv янэсе банк хезмэткэре белэн дэвам иткэн: кызга кредит алырга кинэш иткэн hэм жирле хатын шулай эшлэгэн дэ. Оч йоз кырык тугыз мен сум кvлэмендэ кредит алып, ул банкомат аша билгесез реквизитлар буенча акча кvчергэн. Алга таба хокукка каршы гамэллэрне булдырмау максатыннан максималь лимит белэн кредит картасын рэсмилэштерv талэп ителэ. Алынган 80 мен сумны Саранскта яшэvче хатын шулай ук эйтелгэн счетларга кvчергэн. Шуннан сон билгесез кеше, бераздан анын белэн элемтэгэ керэчэген эйтеп, сvзен туктаткан.
Февраль ахырында зыян кvрvчегэ иминият агенты шалтыраткан, ул уздырыла торган тикшерv hэм алда торган тентvлэр hэм аларны кон фискациялэv ихтималы белэн бэйле рэвештэ декларациялэргэ кирэк булган акчасы юкмы дип кызыксынган. Куркып, хатын ойдэ 1 миллион 570 мен сум саклавын хэбэр итэ, ул банкомат аша шалтыратучы кvрсэтмэсе буенча акчасын шулай ук куркынычсыз счетка кvчерэ. Финанс операциясен уздырганнан сон жинаятьче энгэмэне озэ, э зыян кvрvче барысы турында да иренэ сойлэгэн, э ул полициягэ морэжэгать итэргэ кинэш иткэн.
Биредэ яшэvче хатынга китерелгэн зыян 1 миллион 999 мен сум тэшкил иткэн. Россия Эчке эшлэр министрлыгынын Саранск шэhэре буенча идарэсе кисэтэ: уяу булыгыз! Оченче затларнын шалтыратуларына ышанмагыз, алар vзлэрен банклар, хокук саклау органнары хезмэткэрлэре дип таныштыралар hэм сезнен счетлар буенча шикле операциялэр турында хэбэр итэлэр. Бернинди очракта да билгесез кешелэргэ телефон аша vзегезнен шэхси мэгълvматларыгызны (банк карталарынын номерлары hэм CVC-кодлары, СМС-хэбэрлэрдэн бер тапкыр кулланыла торган парольлэр, паспорт мэгълvматлары) хэбэр итмэгез. Акчаларыгызны куркынычсыз счетларга кvчермэгез. Сездэ туган барлык сорауларны шэхсэн хэл итv очен банкнын якындагы бvлегенэ морэжэгать итегез. Yзегезне алдарга ирек бирмэгез! Мошенниклардан сакланунын башка ысуллары турында сез «Вестник Киберполиции России» hэм «Стопмошенник13» телеграм-каналларына языпып белэ аласыз.